**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4324**
**26.05.2023**

Башкарма комитетның 2022 елның 3 октябрендәге 5187 номерлы карары белән расланган социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 3 октябрендәге 5187 номерлы карары белән расланган социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«1) Россия Федерациясе гражданы паспорты яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесне раслаучы башка документ;»;

2) 2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтләнгән экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.»;

3) 3.3.2.1 пунктта 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан запросның электрон формасының һәр кырын тутыру процессында, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал запросның электрон формасының дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, турыдан-туры запросның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

4) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 3.8 пункт өстәргә:

«3.8. Гомуми билгеләре буенча, шул исәптән аны алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә мөнәсәбәтле рәвештә берләштерелгән гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә муниципаль хезмәт күрсәтү.

Муниципаль хезмәт гариза бирүченең категориясенә һәм мөрәҗәгатьнең нигезенә бәйсез рәвештә күрсәтелә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов